СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2017 елның «29» декабреннән** **№32-187**

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль район Советы регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»**

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль район Советы регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

- 4 бүлекнең исемендә «Совет рәисе урынбасары» сүзләрен «муниципаль район Башлыгы урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

- 16 статьяда «район Советы Рәисе урынбасары» сүзләрен «муниципаль район Башлыгы урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

- 20 статьяда «район Советы Рәисе урынбасары» сүзләрен «муниципаль район Башлыгы урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

- 30 статьяда «район Советы Рәисе урынбасары» сүзләрен «муниципаль район Башлыгы урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

- 59 статьяны «ачык тыңлаулар үткәрелә.» сүзләреннән соң «, муниципаль берәмлек Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (устав) яки Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен әлеге норматив актларга туры китерү максатларында төгәл яңарту рәвешендә үзгәрешләр кертелү очракларыннан тыш» сүзләре белән тулыландырырга»;

- 61 статьяның 1 өлешендә «район Советы Рәисе урынбасары» сүзләрен «муниципаль район Башлыгы урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

турындагы мәсьәлә яшерен тавыш бирү юлы белән хәл ителә, әгәр Совет тавыш бирүнең башка тәртибен билгеләмәсә» сүзләрен «Район Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү конкурс нигезендә башкарыла. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына конкурс үткәрү тәртибе район Советы карары белән билгеләнә. Конкурс шартлары, аны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында белешмәләр, контракт проекты массакүләм мәгълүмат чараларында конкурс уздырылган көнгә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга тиеш»;

- 68 статьяның 2 өлешендә «Совет депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелеге аның өчен тавыш бирсә, Башкарма комитет Җитәкчесен билгеләү турында карар кабул ителгән дип санала» сүзләрен «Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатлар арасыннан тәкъдим ителгән зат район Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башлыгы** **В. М. Козлов**